**МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**13.07.2018** **№3л/с**

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында Нигезләмәне раслау хакында

2004 елның 27 июлендәге 79 номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында» дип исемләнгән Федераль закон, 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру турында» дип исемләнгән Россия Федерациясе Президенты Указы, 2018 елның 31 мартындагы 397 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертү буенча конкурслар уздыруның бердәм методикасын раслау турында» дип исемләнгән карары, 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, 2011 елның 14 мартындагы 127-УП номерлы «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәтенә кадр резервлау турында Нигезләмәне раслау турында» һәм 2015 елның 11 декабрендәге 1192-УП номерлы «Татарстан

Республикасы дәүләтү граждан хезмәтендә булган хезмәткәрләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына дәгъва кылучы затлар өчен тест уздыру мәсьәләләре» дип исемләнгән Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында Нигезләмәне расларга.

2. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

**Министр** **Д.И.Фәттахов**

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре министрлыгының
2018 елның 13 июлендә 3 л/с
номерлы боерыгы белән
Расланган

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАН ХЕЗМӘТЕНЕҢ ВАКАНТЛЫ ВАЗЫЙФАСЫН БИЛӘҮГӘ (КАДРЛАР РЕЗЕРВЫНА КЕРТҮГӘ) КОНКУРС УЗДЫРУ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру буенча конкурс комиссиясенең (моннан соң – конкурс комиссиясе) эшләү чорлары һәм тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында (моннан соң – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру методикасы билгеләнә.

Конкурс (алга таба – конкурс) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт хезмәтенә карата тигез дәрәҗәдә үтеп керә алуы буенча конституциячел хокукларын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукын тәэмин итә.

1.2. Конкурс Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында Нигезләмәдә күрсәтелгән тәртиптә һәм шартларда, 2005 елның 1 февралендәге 112

номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс турында» дип исемләнгән Россия Федерациясе Президенты Указы, 2011 елның 14 мартындагы УП-127 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә кадрлар резервы турында Нигезләмәне раслау турында» дип исемләнгән Татарстан Республикасы Президенты Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләтграждан хезмәтенә кадрлар резервы турында Нигезләмә, 2018 елның 31 мартындагы 397 номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыруның бердәм методикасын раслау турында» дип исемләгән Россия Федерациясе карары нигезендә расланган Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыруның бердәм методикасы нигезендә уздырыла.

1.3. Министрлыкта Конкурс түбәндәге очракларда уздырылмый:

билгеле-бер срокка «җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясенә кергән вазыйфалар билгеләнгәндә;

сроклы хезмәт контракты төзелгәндә;

2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында» дип исемләнгәнФедераль законның 28нче матдәсенең 2нче өлеше, 31нче матдәнең 1нче елеше, 60.1нче матдәнең 9нчы өлешендә күрсәтелгән очракларда граждан хезмәтендәге зат икенче бер граждан хезмәтенә билгеләнгәндә;

Граждан хезмәтенә кадрлар резервына кертелгән граждан хезмәткәре (гражданины) граждан хезмәте вазыйфасына билгеләнгәндә.

1.4. Конкурс түбәндәге очракларда үткәрелмәскә мөмкин:

Министрлык боерыгы нигезендә, дәүләт сере белән эш итә торган граждан хезмәтенең аерым вазыйфаларына билгеләнгәндә;

Министрлык боерыгы нигезендә, граждан хезмәтенең кече төркем граждан хезмәте категориясенә караган вазыйфага билгеләнгәндә.

1.5. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

сәләтләре һәм профессиональ әзерлеге нигезендә граждан хезмәтенә тигез дәрәҗәдә үтеп керүдә Россия Федерациясе гражданнарының конституциячел

хокукларын, шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукларын тәэмин итү;

граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча аеруча туры килә торган кандидатларны федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм конкурста катнашуга кертелгән кандидатларның гомуми саны арасыннан сайлап алу;

Министрлыкның кадрлар резервын формалаштыру.

1.6. Конкурсларны үткәргәндә хәл ителә торган мәсьәләләр:

барлык кандидатлар өчен дә алар тарафыннан конкурс биремнәре һәм процедуралары үтәлгәндә тигез шартларны тәэмин итү;

кандидатларны объектив һөнәри әһәмиятле критерияләр нигезендә бәяләү;

конкурста катнашучылар арасыннан, конкурс процедуралары барышында алынган объектив һәм нигезле күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфалары (кадрлар резервына кертү) таләпләренә җавап бирә торган затларны ачыклау.

1.7. Конкурс Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министры (моннан соң министр) карары белән граждан хезмәтенә вакантлы урын булган структур бүлек җитәкчесенең мөрәҗәгате нигезендәигълан ителә (әлеге Нигезләмәгә беркетелгән 1нче Кушымта).

1.8. Министрлыкның кадрлар резервына кертү буенча конкурс Министрлыкның дәүләт хезмәте, кадрлар һәм юридик эшләр секторы тарафыннан Министрлыкның булган кадрлар резервы һәм мөмкин булган махсус граждан хезмәтен куллану ихтималы буенча еллык нәтиҗәләре нигезендә уздырала.

Министрлыкның кадрлар резервына кертү буенча конкурс Министрлыкның конкурс комиссиясе тарафыннан әлеге Нигезләмәдә күрсәтелгән тәртиптә уздырыла.

## 2. Конкурс комиссиясен формалаштыру һәм аның эшләү тәртибе

2.1. 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын билгеләүгә конкурс турында» ңип

исемләнгән Россия Федерациясе Президенты карары нигезендә Министрлыкта даими нигездә эшләүче конкурс комиссиясе төзелә. Конкурс комиссиясенең составы Министрлык боерыгы белән раслана. Комиссия составына кертелгән вазыйфаи затлар исемлегенә үзгәрешләр булган очракта, Министрлык боерыгы белән тиешле үзгәрешләр кертелә.

2.2. Конкурс комиссиясе Рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.3. Конкурс комиссиясе эшчәнлеге белән конкурс комиссиясе рәисе җитәкчелек итә, утырышларның көнен билгели, көн тәртибен раслый, конкурс комиссиясе утырышларында рәислек итә, тиешле документларны имзалый. Комиссия рәисе булмый торганда аның хокукларын һәм бурычларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясе сәркатибе конкурс комиссиясенең эшен тәэмин итә (гаризаларны кабул итә, эшләрне формалаштыра, конкурс комиссиясе утырышлары карарларын рәсмиләштерә һ.б.).

2.4. Министрлыкның Конкурс комиссиясе составына министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче, дәүләт хезмәте, кадрлар һәм юридик мәсьәләләр секторы вәкилләре, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкилләре, Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрелә торган структур бүлекчәсенең структур бүлекчәсе җитәкчесе, Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук Министрлык чакыруы буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан бәйсез экспертлар – граждан хезмәтенә бәйле мәсьәләләр буенча белгечләр сыйфатында экспертларның шәхси мәгълүматларын күрсәтмичә чакыртыла торган фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар вәкилләре керә.

Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләренең конкурс комиссиясе составына кертелүгә тәкъдим ителгән кандидатуралары шул совет тарафыннан министр соравы буенча тапшырыла.

Бәйсез экспертлар саны конкурс комиссиясендәге әгъзаларның гомуми саныннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итә.

2.5. Алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итүче

белешмәләрдән файдаланууга бәйле булган граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздырылганда конкурс комиссиясе составы Россия Федерациясенең дәүләт сере турында законнары нигезләмәләрен исәпкә алып төзелә.

2.6. Конкурс комиссиясе составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеге калмаслык итеп төзелә.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми исәбендәге кимендә өчтән ике өлеше катнашса, ул тулы хокуклы булып санала. Конкурс комиссиясе утырышын фәкать комиссиянең граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалары составында гына үткәрү – рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс комиссиясе:

конкурс уза торган датаны, урынны һәм конкурс тәртибен, кандидатларны бәяләү методларын билгели;

дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына дәгъва кылучы затларны конкурс уздыру шартлары белән таныштыра һәм сорауларына җавап бирә;

кандидатлардан килгән сораулар, гозерләр буенча конкурс документларын бирә;

дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына дәгъва кылучы затлар тарафыннан тапшырылган документларны тикшергәннән соң, конкурс комиссиясе конкурсның икенче этабына уздырылган кандидатлар исемлеген раслый;

кандидатларның тиешле шартларга туры килү-килмәвенә бәя бирә;

конкурска нәтиҗә ясый, кандидатны җиңүче дип билгели, кадрлар резервына кертүгә тәкъдим итә.

2.9. Конкурс комиссиясе карары кандидат юклыгында кабул ителә һәм аны вакантлы вазыйфага билгеләү яки билгеләмәү өчен нигез булып тора .

2.10. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре комиссия рәисе, рәис урынбасары, җаваплы сәркатип һәм комиссия утырышында катнашкан комиссия әгъзалары имзалаган конкурс комиссиясе беркетмәсе белән теркәлә. Конкурс комиссиясенең карарында дәүләт граждан хезмәтенә беренче тапкыр кабул ителгән

гражданның яки Министрлыкның бер  вазыйфасыннан икенче вазыйфасына яки төркеменә яки категориясенә күчерелә торган гражданлык хезмәткәренең сынау срогын озынайту турында киңәш булырга мөмкин.

2.11. Конкурсны үткәрү, конкурс комиссиясе эшен турыдан-туры оештыру һәм тәэмин итү эше Министрлыкның дәүләт хезмәте, кадрлар һәм юридик мәсьәләләр секторы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 3. Конкурсның катнашучылар

3.1. Конкурста катнашу хокукына 18 яше тулган, Россия Федерациясенең дәүләт телен белгән һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары тарафыннан билгеләнгән Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына карата булган квалификацион таләпләргә туры килгән Россия Федерациясенең һәр гражданины хокуклы.

Гражданлык хезмәткәре конкурс уздырылган вакытта нинди вазыйфа башкаруына карамастан гомуми шартлар нигезендә конкурста катнашырга хокуклы.

3.2. Конкурста катнашуга Министрлыкта дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) карата квалификация таләпләренә җавап биргән һәм тиешле документларны вакытында тапшырган гражданнар уздырылалар.

3.3. Гражданин (граждан хезмәткәре) граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) карата квалификация таләпләренә җавап бирмәве аркасында, шулай ук Федераль законда билгеләнгән чикләүләренә бәйле рәвештә конкурста катнашуга кертелми.

3.4. Министрлыкта дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатларга таләпләр дәүләт граждан хезмәте турында  Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнә һәм Министрлык боерыгы белән раслана.

3.5. Конкурста катнашу теләген белдергән гражданин Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра::

а) әлеге Нигезләмәгә беркетелгән 2нче кушымтага туры китерелгән формада шәхси гариза;

б) Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган формада тутырылган һәм

имзаланган анкета, фото белән;

в) паспорт яки аны алмаштыра торган документ (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә) күчермәсе;

г) кирәкле һөнәри белемне, квалификацияне һәм эш стажын раслый торган документлар:

хезмәт кенәгәсенең (хезмәт итүгә (эшләвенә) бәйле эшчәнлек беренче мәртәбә гамәлгә ашырыла торган очраклардан кала) нотариаль яки хезмәт итү (эшләү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе яки гражданинның эшләвен (хезмәт эшчәнлеген) раслый торган бүтән документлар;

белем алу турында һәм квалификация турында документларның күчермәләре, шулай ук, ихтыяры буенча, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрүне яки бирелүне раслый торган документларның, фәнни дәрәҗә, фәнни исем бирелү турында документларның нотариаль яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәләре;

д) гражданинда граждан хезмәтенә керүгә яки аны үтүгә комачаулый торган чирләрнең юклыгы турында документ;

е) 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында» дип исемләнгән Федераль закон, башка федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты боерыклары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары тарафыннан каралган башка төр документлар.

3.6. Конкурста катнашу теләген белдергән, Министрлыкта дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгән граждан хезмәткәре Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министры исеменә шәхси гариза тапшыра.

3.7. Гражданинның (граждан хезмәткәренең) ризалыгы белән аңа дәүләт серен яки закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга рөхсәт бирү процедурасы рәсмиләштерелә, әгәр гражданин (граждан хезмәткәре) биләү өчен дәгъва белдергән граждан хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү мондый белешмәләрдән файдалануга бәйле булса.

Граждан тарафыннан яллаучы якның вәкиле исеменә тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә тапшырылган белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә автоматлаштырылган рәвештә тикшерелә

Гражданлык хезмәткәре тарафыннан конкурста катнашу өчен дип тапшырылган документлар, дәүләт граждан хезмәтенең югары категория вазыйфаларына дәгъва кылган очракта гына тикшерелә.

Граждан тарафыннан башлык исеменә тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә тапшырылган белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә автоматлаштырылган рәвештә тикшерелә.

3.8. Әлеге Нигезләмәнең 3.4 һәм 3.5 пунктларында күрсәтелгән документлар аларны кабул итү турында «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы рәсми сайтында (моннан соң – Федераль мәгълүмат системасы) игълан урнаштырылган көннән башлап 21 календарь көне эчендә Министрлыкка гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан шәхсән, почта аша җибәреп яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә күрсәтелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон рәвештә җибәрелә.

3.9. Документларны үз вакытында тапшырмау, тапшырмауны аклый алырдан сәбәпләр булмау, документларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү, кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданиннан (граждан хезмәткәреннән) аларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

Сәбәпле рәвештә документларны үз вакытында тапшырмаганда, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырганда Министр аларны карап тикшерүнең вакытын кичектерергә хокуклы.

## 4. Конкурсны уздыру методикасы

4.1. Конкурс уздырганда, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары тарафыннан тыелмаган кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методикасына нигезләнгән конкурс биремнәре һәм процедуралары кулланыла.

4.2. Кандидатларның квалификацион таләпләргә туры килү-килмәвен бәяләү дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы кайсы категориягә һәм төркемгә керүе белән бәйле. Әлеге Нигезләмәгә беркетелгән 3нче кушымтада күрсәтелгән

методлар һәм әлеге Нигезләмәгә беркетелгән 4нче кушымтада күрсәтелгән бәяләү методын сурәтләү нигезендә башкарыла бәяләү процессы.

4.3. Кандидатларның профессиональ дәрәҗәсен, аларның квалификация таләпләренә туры килүен бәяләү критерийлары Министрлыкта дәүләт граждан хезмәтендәге затка карата булган квалификацион таләпләр нигезендә эшләнә.

Конкурс уздырылган вазыйфаның группасы һәм категориясенә бәйле рәвештә, конкурсантларны бәяләү критерийлары һәм бәяләү методлары үзгәрергә мөмкин.

4.4. Кандидатларны сайлап алу һәм чагыштыру алар башкарган конкурс биремнәре нәтиҗәләре һәм конкурс процедураларын узу нәтиҗәсендә тормышка ашырыла.

4.5. Конкурс ике этапта үткәрелә.

4.5.1. Беренче этапта кадр хезмәте тарафыннан түбәндәгеләр оештырыла::

а) конкурс уздыру турында мәгълүмат әзерләнә һәм Министрлыкның рәсми сайтында һәм «Россия Федерациясе дәүләт хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмати системасы» дип исемләнгән Федераль мәгълүмат системасының рәсми сайтларында урнаштырыла. Ул үз эченә түбәндәгеләрне ала:

граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасының (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасының) аталышы;

дәүләт гарждан хезмәтенең вакантлы вазыйфалар категориясе һәм төркемнәре;

әлеге вазыйфаны биләү өчен кандидатка белдерелә торган квалификация таләпләре;

гражданлык хезмәтен башкару шартлары;

граждан хезмәтен узу шартлары, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен кандидатлар тарафыннан тапшырыла торган документлар һәм материаллар исемлеге нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты,

конкурс булырга мөмкин булган көн, урын һәм утырышны уздыру тәртибе, бәяләү методлары турында мәгълүмат;

гражданинның (граждан хезмәткәренең) квалификация таләпләренә туры килүе (һөнәри белем дәрәҗәсе, граждан хезмәте (бүтән төрле граждан хезмәтенең) стажы яки белгечлеге буенча эшләү стажы (тәҗрибәсе), әзерлек юнәлеше, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган һөнәри белемнәре һәм күнекмәләре

нигезләмәсе;

квалификацион тестны конкурстан тыш шартларда узып булу мөмкинлеге турында мәгълүмат.

б) кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларны тикшерелә. Электрон рәвештә тәкъдим ителгән мәгълүмат, Россия Федерациясе Хөкүмәте тәртибе нигезендә, автоматик рәвештә тикшерелә. Россия Федерациясе законнары нигезендә Министрлыкта шәхси мәгълхматларны кабул итү өлкәсендә хокукый, оештыру һәм техник чаралар кылына.

в) гражданинның (граждан хезмәткәренең) квалификация таләпләренә туры килүе (һөнәри белем дәрәҗәсе, граждан хезмәте (бүтән төрле граждан хезмәтенең) стажы яки белгечлеге буенча эшләү стажы (тәҗрибәсе), әзерлек юнәлеше, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган һөнәри белемнәре һәм күнекмәләре) тикшерелә.

Конкурсның беренче этабы кабул итү турында игълан урнаштырылган көнне башлана һәм 21 көннән дә иртәрәк тәмамлана алмый.

4.5.2. Конкурсның икенче этабы документлар кабул итеп бетергән көннән 30 календар көннән дә соңармыйча башланып китә.

4.6. Тикшерү барышында гражданинның федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары нигезендә граждан хезмәтенә керүенә комачау итүче шартлар ачыкланган очракта, аңа катнаштырудан кире кагуның сәбәпләре турында министр тарафыннан язмача рәвештә хәбәр ителә. Әгәр гражданин конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган булса, конкурста катнаштырудан кире кагу сәбәпләре хакында хәбәрләмә аңа дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

4.7. Конкурста катнашуга кертелмәгән, вакантлы вазыйфаны биләү өчен дәгъва белдергән зат әлеге карарга Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять белдерергә хокуклы.

4.8. Министрлыкта граждан хезмәтенең бер вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) карата куелган квалификация таләпләренә җавап бирә торган кимендә ике кандидатның булуы конкурсның

беренче этабын төгәлләү шарты булып тора, бу хәл кандидатларны алга таба сайлау мөмкинлеген тәэмин итә.

Кандидатлар булмаганда яисә вазыйфага карата квалификация таләпләренә җавап бирә торган бары тик бер генә кандидат булган очракта, конкурс узмаган дип таныла. Бу очракта бердәнбер кандидатка таләп ителүче кандидатлар саны булмауга бәйле рәвештә конкурсның узмаган дип танылуы хакында язмача хәбәр ителә.

4.9. Конкурс комиссиясенең конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан имзаланган, куелган таләпләргә мөмкин кадәр туры килгән, конкурста катнашуын дәвам итәргә лаеклы дип тәкъдим ителгән кандидатлар исемлеге төзүе турындагы карары конкурсның беренче этабының нәтиҗәсе булып тора.

4.10. Конкурсның беренче этабы тәмамлангач министр конкурсның икенче этабын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында карар кабул итә. Дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга рөхсәт рәсмиләштерелгән очракта, конкурсның икенче этабын уздыру чорын министр билгели.

4.11. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча сектор конкурсның икенче этабы башланырга кимендә 15 календарь көне кала, Министрлыкның рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында аның уздырылу датасы, урыны һәм вакыты хакында мәгълүмат урнаштыра һәм кандидатларга тиешле хәбәрләрне язмача рәвештә, бу вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрә.

4.12. Министрлыкта конкурс оештыру «Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт кадрлары составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла (моннан соң – Бердәм кадрлар мәгълүмат системасы).

4.13. Конкурсны уздырганда конкурс комиссиясе кандидатларны алар тарафыннан тапшырылган белеме, граждан яисә башка төрле дәүләт хезмәтен узуы, башка төрле хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруы турындагы документлар нигезендә,

шулай ук тест уздыруны, шәхси әңгәмә уздыруны, язмача эшне, документ проектын әзерләүне үз эченә алырга мөмкин булган бәяләү методларын кулланып, конкурс процедуралары нәтиҗәләре нигезендә бәяли. Конкурс уздырыла торган вазыйфалар төркеменә һәм категориясенә карап, төрле методлар кулланылырга мөмкин. Бу вакытта кандидат белән тест һәм шәхси әңгәмә уздыру барлык кандидатлар өчен дә мәҗбүри методлар булып тора.

4.15. Кандидатларның конкурс биремнәрен контрольләү максатыннан чыгып, конкурс процедурасы вакытында конкурс комиссиясе әгъзалары да була. Министр карары нигезендә кандидатлар конкурс биремнәрен үтәгәндә һәм комиссия утырышы булганда видео- һәм (яки) аудиозапись яки конкурс процедурасының стенограммасы яздырылырга мөмкин.

4.16. Конкурс комиссиясе утырышында һәр кандидат белән шәхси әңгәмәләр уздырыла. Шул әңгәмә барышында кандидат белән башка биремнәрнең нәтиҗәләре сөйләшенә, һөнәри дәрәҗәне билгеләү өчен сораулар бирелә. Кандидат белән конкурс комиссиясе тарафыннан кара-каршы шәхси әңгәмә уздырмыйча конкурста җиңүчене билгеләү турында конкурс комиссиясе карарын кабул итү рөхсәт ителми.

4.17. Кандидат белән шәхси әңгәмә тәмамланганнан соң конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы әлеге нигезләмәгә беркетелгән 2нче кушымтага туры китерелгән формада төзелә торган конкурс бюллетененә, кирәк булганда конкурс комиссиясе әгъзасы тарафыннан кабул ителгән карарны нигезләүче кыскача дәлилләмә белән, кандидатны бәяләү нәтиҗәсен терки.

4.18. Кандидатның ахыргы баллы кандидатка конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан шәхси әңгәмә нәтиҗәләре буенча куелган балларның һәм кандидатның тест һәм башка төрле аналогик конкурс биремнәрен үтәү йомгаклары буенча җыелган балларның уртача арифметик суммасы буларак билгеләнә.

Кандидатларның йомгак балларын чагыштыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе сәркатибе кандидатлардан рейтинг билгели.

4.19. Конкурс уздыру нәтиҗәсендә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасы) буенча барлык кирәкле таләпләргә җавап бирә торган кандидатлар ачыкланмаган очракта, конкурс комиссиясе өстәмә конкурс сынауларын үткәрү турында карар кабул итәргә яки яңа конкурс уздыру турында тәкъдим кертергә хокуклы.

4.20. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына конкурста җиңүчене (кадрлар резервына кертү өчен кандидатны (кандидатларны)) билгеләү турында конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү нигезендә утырышта катнашкан әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

4.21. Ике яки аннан да күбрәк кандидат тарафыннан бертигез күләмдә баллар тупланса, конкурс комиссиясе рәисенең фикере соңгы сүз булып тора.

4.22. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре Конкурс комиссиясенең конкурс эше нәтиҗәләре буенча әлеге нигезләмәгә беркетелгән 6нчы протокол һәм әлеге нигезләмәгә беркетелгән 7нче кушымта буенча формалаша.

Беркетмәдә кандидатлар исемлеге, аларның туплаган баллары һәм аларның конкурс комиссиясе карары нигезендә ничәнче урын яулавы турындагы мәгълүмат күрсәтелә.

4.23. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча конкурс нәтиҗәләре нигезендә министрның конкурста җиңүчене граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү турында боерыгы чыгарыла һәм аның белән хезмәт контракты төзелә. Конкурс комиссиясе шулай ук тәкъдим холкына ия булган, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча конкурста җиңмәгән, ләкин һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәягә лаек булган кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында карар кабул итәргә хокуклы.

4.24. Кадрлар резервына конкурс комиссиясе тарафыннан тупланган балларының гомуми суммасы максималь баллның 50 процентыннан азрак булган кандидатлар арасыннан да кандидатлар тәкъдим ителергә мөмкин.

4.25. Кандидатның аны граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча кадрлар резервына кертүгә ризалыгы язмача формада яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында рәсмиләштерелә.

Кандидатның ризалыгы белән, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы караган шул ук төркем граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен, аны кадрлар резервына кертү турында министр боерыгы чыгарыла

4.26. Кандидат конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять белдерергә хокуклы.

4.27. Конкурс нәтиҗәләре хакында хәбәрләр ул тәмамланганнан соң 7 көнлек

